МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ № 71/о БОЕРЫК

«06» 04 2017

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 14 декабрендәге 222/о-1 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 һәм 55 статьялары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 14 декабрендәге 222/о-1 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 29 июнендәге 114/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын

эксплуатациягә тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктының өченче абзацын төшереп калдырырга;

1.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2015, № 29 (1 кисәк), 4344 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);»;

2.4 пунктының «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының беренче абзацында «10» саннарын «җиде» сүзенә алмаштырырга;

2.5 пунктында «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2 пунктчасында «җир кишәрлегенең» сүзләреннән алда «төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган» сүзләрен өстәргә;

11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясы таләпләре нигезендә әзерләнгән техник план».»;

2.9 пунктының 2 пунктында «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата җир кишәрлегенең төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә яисә, линияле объектны төзү, реконструкцияләү, капиталь төзекләндерү очрагында, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты таләпләренә җавап бирмәве;»;

түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) төзелешкә рөхсәт алу өчен җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын тапшыру датасына Россия Федерациясенең җир һәм бүтән төрле законнары нигезендә шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән чикләмәләргә җавап бирмәве.»;

2.13 пунктында «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы» графасында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «, шул исәптән электрон рәвештә» сүзләрен өстәргә;

3.4.2 пунктының өченче абзацында «3 эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1 Бүлек белгечләре документларның булуына һәм дөрес рәсмиләштерелүенә тикшерү уздыралар һәм капиталь төзелеш объектын карыйлар.

Бүлек белгечләре төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын карау барышында мондый объектның төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән, җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга карата таләпләргә, капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата төзелешкә

рөхсәт алу өчен тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелү датасына билгеләнгән таләпләргә яисә, линияле объектны төзү, реконструкцияләү очрагында, территорияне планлаштыру проектына һәм территорияләрне ызанлау проектына, проект документлары таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренә җавап бирүен, аерым торак төзелеше объектын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру очракларыннан тыш, шулай ук Россия Федерациясенең җир һәм башка төрле законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә туры килүен тикшерәләр.

Шушы пунктта билгеләнүче процедуралар тапшырылган документларның комплектлылыгын тикшергәннән соң (шушы Административ регламентның 3.4.1 процедурасы тәмамлангач) өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерелгән документлар һәм объектны карау. »;

3.6.2 пунктының алтынчы абзацында «2 эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.3 пунктының бишенче абзацында «2 эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

дәүләт хезмәтен күрсәтүнең блок-схемасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта булып бирелә);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитларын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта булып бирелә).

3. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.


5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА
МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының
капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә
тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына
(Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының
2017 елның «06» 04 № 71/0
боерыгы редакциясендә)
2 нче кушымта

# Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы



Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның «06» 04
№ 71/0 боерыгы редакциясендә)
6 нчы кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура
һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары | **231-14-03** | Aleksey.Frolov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | **231-14-05** | Ilshat.Gimaev@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | **231-17-08** | Dinar.Sagdatullin@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | **231-14-57** | Dmitriy.Yasakov@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру бүлеге башлыгы | **264-77-24** | Yuriy.Azin@tatar.ru |